2023 елның 6 ноябре №3

# КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 06 ноябрендә узган “2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 10000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча чишүгә юллау белән килешәсезме?- Яр буе Морквашы авылының Калуга урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау,- дигән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 8 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 5 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенының 5 катнашучысы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде, тыелдылар - җыенның 0 катнашучысы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы авылының бер өлеше территориясендә гражданнар җыены булган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. “2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 10000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча чишүгә юллау белән килешәсезме?- Яр буе Морквашы авылының Калуга урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлауҗирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авылы җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х.Гаязов